**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Староматакского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Матак авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422890, РТ, с. Старые Матаки, ул. Центральная , 4
тел: : 8 (84346) 79-2-12

Адресы: 422890, РТ, Иске Матак авылы, Центральная ур.,4
факс: 8 (84346) 79-2-12

**РЕШЕНИЕ** Иске Матак авылы **КАРАР**

2018 елның 19 ноябре 31№

ТР Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукы һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә һәм җирле референдумда тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре, референдум нәтиҗәләре турында референдум нәтиҗәләре хакында «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы ИК» 749 номерлы УИК (ИКМО) беркетмәсе нигезендә

Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә гражданнардан үзара салым җыюны кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны узган, ә референдум нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Җирле референдумда түбәндәге мәсьәләләр буенча карарлар кабул ителгән дип санарга:

"Иске Матак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 600 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән затлардан тыш, үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам яктырткычларын ремонтлау, лампаларны, яктырткычларны алыштыру һәм кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар түләүгә - 100 сум;

- торак пунктларда поселок юлларын тәзекләндерүгә һәм карап тотуга - 265 сум;

- Иске Матак авыл җирлегенең үзәк паркын киртәләү өчен койма сатып алу һәм урнаштыру өчен - 50 сум;

- су белән тәэмин итүнең урам системасын ремонтлау, су башнясының электр энергиясен куллану һәм суның лаборатор-инструменталь тикшеренүләре өчен - 100 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә, контейнерлар сатып алуга (белгеч эше өчен түләү) - 85 сум.

тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегендә референдумда 329 катнашучы кертелгән;

референдумда тавыш бирүдә катнашучылар саны 304, бу 92,4 % тәшкил итә.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлегенең тавыш бирү йомгакларын расларга.

4. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге мәгълүмат стендында бастырырга.

Совет Рәисе,
Иске Матак авыл җирлеге башлыгы Н.И.Кудряшов